«Ык белән Идел арасында шәһит...»



Әгерҗе төбәгендәге татар зиратларында сакланган, тарихи һәм фәнни җәһәттән игътибарга лаеклы элекке кабер ташларын гыйльми өйрәнү максаты белән 2000 елның яз һәм көз айларында эпиграфик экспедицияләр үткәргән идек. Аның нәтиҗәләре буенча «Гасырлар авазы — Эхо веков» журналында мәкаләбез дә басылды[1]. Анда (шулай ук башка язмаларыбызда да) Салагыш халкы «Әүлия кабере» дип йөртә торган иң борынгы ташъязманы таба алмыйча калуыбыз әйтелгән иде. Ниһаять, без аны табып, җентекләп өйрәндек һәм бу язмабыз нәкъ менә шул ядкарь — 1658 елның көзендә һәлак булган өч кешегә куелган таш турында.

Борынгы язмаларны өйрәнүче галим Марсель ага Әхмәтҗанов әлеге ташны 1977 елда күреп укыган һәм бу хакта беренче мәртәбә 1983 елда дөнья күргән мәкаләсендә белдергән иде[2]. Әмма без, әйткәнебезчә, 2000 елның язындагы экспедициябездә Салагыш авылындагы әлеге борынгы ташны таба

алмыйча калган идек. Ул чагында безне ялгыш икенче каберлеккә — халык телендә «Өч тирәк» дип йөртелә торган зиратка юнәлткән булганнар. «Өч тирәк» зираты Салагыш авылыннан ике чакрым чамасы читтәрәк (көньяк-көнбатыштарак). Сөйләнә торган риваятьләргә караганда, ул урында 400-500 еллар элек авыл булган. Койма белән әйләндереп алынган һәм каеннар үсә торган ул каберлектә бернинди дә кабер ташы юк. Ул чагында иске ташъязманы тапмагач, моңа кадәрге мәкаләләребездә М. Әхмәтҗанов өйрәнгән таш безнең тарафтан табылмады дип язган идек[3].

Бу мәсьәләне ачыклап бетерү максатыннан мәгълүматлы кешеләрдән тагын да сораштык. Нәтиҗәдә, Салагыш авылындагы «Әүлия кабере»нең «Өчтирәк зираты»ннан аерым булуын һәм аның «Яңа зират» дип йөртелә торган зират янында гына икәнлеген ачыкладык. Ихтимал, ташъязма да сакланган дир дип, 2007 елның 26 май көнендә Салагыш авылына барып, «Яңа зират»ның авылга караган ягына утыртылган куе наратлыкта «Әүлия кабере»н табуга иреште к. Борынгы ташъязма истәлек, язулар уелган алгы тарафына авышкан хәлдә калкып тора. Ташның текстын укып, тулаем күчереп алдык һәм фоторәсемгә төшердек.

Вак кына итеп уелган язулы, төгәл датасы 1658 елның ноябренә карый торган бу таш Әгерҗе төбәгендәге иң борынгы тарихи истәлек булуы белән әһәмиятле. Аны мулла Дусмәт Теләш улы язган. Әлеге ташта исемнәре уелган затларга бәйле тарихи вакыйгалар турында Россия дәүләт борынгы актлар архивында да мәгълүматлар табылды. Ташка язылганнарны һәм архив чыганакларын җентекләп өйрәнгәч, бу каберташ язмасында исемнәре күрсәтелгән Салагыш кешеләренең Ык елгасы буенда, үз биләмәләрен саклап, руслар белән бәрелеш вакытында һәлак булганлыклары ачыкланды.

Бигәш улы Бикколга һәм аның ике улына уртак куелган 1658 елгы бу ташның биеклеге 110 см, киңлеге 51 см, калынлыгы 9 см. Аның тексты алгы ягында, вак хәрефләр белән 18 юлда уеп язылган. Ташның алгы як өслеге 5,5 см киңлегендәге чыгынкы кайма белән уратып алынган.

Ташъязманың тулы тексты түбәндәгечә:

1)* әл-хәййе әлләзи

2) битеде Теләш угылы Дусмәт хафиз

3) лә йәмүт вә һуа

4) көлли сә-йәмүт калә Аллаһы

5) сөбханәһә вә тәгалә вә ма тәдәррә нәфсин

6) арзи тәмәүт

7) иннә Аллаһы гъәлимүн хәйрүн калә ән-нәби гъәләйһи-с-сәлам

8) көлли нәфсин заикъәт калә [ән-]нәби гъәләйһи-с-сәлам

9) әд-дөнйа сагъәт тәҗгъәлиһа тагъәт ка-

10) -лә ән-нәби гъәләйһи-с-сәлам әд-дөнйа миз[р]агъәт-ел-ахирәт

11) әра әд-дөнйа хәрабән би-и[гъти]бари фәла йәбкъә мәдамән би-л-карари**

12) күрәрмен дөнйаны вәйран бары һәмишә

13) бакый ирмәс йук карары тарих төгә-

14) -л мең узуб алтмыш тугызда ду-

15) -ңуз йылында сәфәр ай[ы]ның ахырында Бигәш

16) угылы Биккол ике угылы берлә Икъ берлә Идел арасында шәһид

17) ли-л-фәнадин даре-л-бәкага рәхмәт кылсун

18) Хак тәга[лә] киҗ те

М. Әхмәтҗанов бер мәкаләсендә шушы таш турында мәгълүмат биреп, түбәндәгечә язган иде.

«Һиҗрәт тарих 1069 руми стиль белән 1659 нчы елга туры килә. Ул вакытларда Икъ-Идел (Чулман. — *М. Ә.*) арасындагы җирләр Бөек Нугай урдасы милке булган. Шунлыктан Чулманның уң ягындагы татарлар сул якка бик тынычлап чыга алмаганнар. Ләкин бу дәвер нугайлар урдасының таркала бару дәвере булып, Мәскәү хөкүмәте аның җирләрен әкренләп үзләштерүгә керешә. Чулманның сул ягына казаклы татарларны утырта башлыйлар. Бу хәлләр шәҗәрәләр белән дә раслана.

* Монда без куйган саннар юлларның тәртибен белдерә.
** 11 нче юл астында тасмасыман бизәк уелган.

Чаллы шәһәре янындагы Бигәш авылы Салагыш каберташында язылган Бигәшнең милке булу ихтималы бар. Бигеш исемле мирза XVII гасырларда хәзерге Әгерҗе төбәгендә яшәгән[4]».

М. Әхмәтҗанов мәкаләсендә бу ташның датасы бер елга ялгыш күрсәтелгән. Чөнки һиҗри 1069 елның сәфәр ае ахыры милади ел исәбе буенча, дөреслектә, 1658 елның ноябренә туры килә.

Таштагы язулар бик вак булуы һәм начаррак күренүе сәбәпледер, М. Әхмәтҗанов 2 нче юлдагы «Дусмәт» дигәннән соңгы, бераз өскәрәк борып язылган «хафиз» сүзен күрмичә калган. Шулай ук текстның 16 нчы юлында Икъ (Ык) һәм Идел сүзләре арасына түбәнге яктан тагын да ваграк хәрефләр белән өстәп уелган «берлә» сүзе дә галимнең игътибарыннан читтә калган.

Бу ташта язылган Бигәш дигән затның исеменә бәйле фаразыбызны без дә моңарчы белдергән идек. Ягъни, Мүшик исемле, хәзерге вакытка беткән авылның элек Бигәш исемендә йөргәнлеген әйтеп, бу атаманың Салагыш янындагы ташта язылган Бигәш белән бәйле булуы ихтимал дидек[5].

Мәскәүдәге архив материалларыннан Салагыш авылы янындагы «Әүлия кабере»нә бәйле тарихи вакыйгаларны бераз ачыклауга иреште к*. Салагыш авылының «башкорт» сословиесендәге** татар кешеләре, үзләренең Ык елгасындагы һәм аңа коя торган башка елга-инешләр, күлләрдәге балык тоту биләмәләрендә 1658 елда руслар белән чыккан низаглары турында белдереп, шикаятнамә язганнар. Салагышның Җөремеш Сөендек улы (Чермыш Сендюков) һәм башка авылдашларының Ык буендагы элек-электән килгән биләмәләре 1656 елда русларга — Кострома Богоявление монастыре игумены*** Герасим һәм аның монахларына бирелгәч, ике арада бәхәс чыккан икән. Бу мәсьәлә тикшерелгәч, чынлыкта да, Салагыш авылы кешеләре Дусмәмәт Теләшев, Әзмәмәт Байгильдин һәм Бигәй Җөремешевнең бөтен авылдашлары белән Ык буендагы уртак биләмәләреннән электән файдаланулары ачыкланган. Ә рус монахлары — бу төбәккә күчерелгәч, Ык Тамагы авылын нигезләп, шунда яшәгәннәр. Архив мәгълүматларына караганда, ул урынга руслар килеп төпләнгәнче, элек-электән татарлар яшәгәннәр. Вятка руслары Нократ елгасы буйлап көймәләрдә йөзеп килеп кабат-кабат талаулар белән тынгысызлаганнан соң андагы татарлар күченеп китәргә мәҗбүр булганнар. Соңгырак гасырларда Кама елгасындагы эре пристаньнәрнең берсе буларак танылган Ык Тамагы авылы хәзерге вакытта Менделеев районына керә.

Архив документында исеме күрсәтелгән Бигәй Җөремешев (Җөремеш Сөендекевнең улы) Салагыш авылы янындагы кабер ташына исеме уелган Бикколның атасы — Бигәш булырга тиеш дип уйлыйбыз. (Бигәй һәм Бигәш — асылда Бикмөхәммәт исеменең кыскартылган вариантлары). Чөнки кабер ташында Бикколның ике улы белән бергә Ык һәм Идел арасында шәһит киткәнлеге уелган. Елы да (1658) туры килә. Күрәсең, алар нәкъ менә шул 1658 елда биләмә өчен руслар белән килеп чыккан низаглашу нәтиҗәсендәге бәрелештә һәлак булганнар. Элекке татар кабер ташларында «шәһит китү» сүзенең «кяферләр» (руслар) белән сугышып һәлак булучыга карата язылганлыгын да игътибарга алырга кирәк.

Архив материалларыннан күренүенчә, бу ташны язып куйган Теләш улы Дусмәт тә Салагыш кешесе булган икән. Ташта уелган Дусмәт һәм архив документында теркәлгән Дусмәмәт исемнәре — бер үк Дусмөхәммәтнең кыскартылган вариантлары.

1660 елгы башка бер архив документында да Бигәй Җөремеш улы белән Дусмәмәт Теләш улы бүтән авылдашлары белән Ык буендагы үз биләмәләренә

---

* Бу мәсьәлә Россия борынгы актлар дәүләт архивының 248, 1173, 1306 һәм 1324 нче фондларындагы берничә саклау берәмлегендә тасвирланган.

** Бу төбәктәге татарларның «башкорт» сословиесенә нисбәтләре турында моңарчы тәфсилләбрәк аңлатып язганлыктан (Мәрданов Р., Һадиев И. Әгерҗе төбәге тарихы. – Казан, 2003. – Б. 14-17; Гыйбрәт, яки Чукындыру чукмары / Кереш мәкалә, документлар һәм искәрмәләрне Р. Мәрданов әзерләде // Гасырлар авазы — Эхо веков. − 2000. − № 1/2. − Б. 105, 111), бу мәсьәләгә киңәеп тукталмыйбыз.

*** Игумен — православие христианнарында монастырь рәисе.

баргач, тагын руслар белән гауга чыкканлыгы язылган. Ул чагында салагышлыларның тотылган биш олау балыкларын, җиде атларын һәм чаналарын, коралларын һәм башка кирәк-яракларын руслар үзләренә алып, татарларны богаулап куйганнар. Әлеге низаглы мәсьәләне тикшергәндә 1625 һәм 1640 еллардагы биләмә хокукы биргән документларда (грамоталарда) Җәремеш Сөендек улының исеме телгә алынган. Архив чыганакларында Җәремешнең абыз, ягъни мулла булганлыгы да теркәлгән.

Гомумән, салагышлыларның Кама елгасы аръягындагы күп кенә татар авылларын нигезләүгә турыдан-туры мөнәсәбәтләре булуы элеккеге чорлардагы тарихи сәбәпләргә бәйле.

Моннан 350 ел элеккеге тарихи вакыйгалар ядкаре булган әлеге борынгы ташъязма истәлек, тарихи әһәмияте белән берәүттән, үзенең палеографик үзенчәлекләре җәһәтеннән дә кызыклы.

Ташның тексты гарәп язуының нәсех дип атала торган төренә өлешчә мөхаккакъ һәм рәйхани язуларының чалымнары кушылган рәвештә нәфис итеп уеп язылган. 11 нче һәм 12 нче юлларны тар гына (3 см чамасы киңлектәге) тасмасыман бизәк аерып тора. Бизәкнең өске өлешендәге 1, 3-11 юллар гарәп телендә, 2 нче юлы татарча, ә түбән ягындагы җиде юл да (12-18 юллар) тулаем диярлек татар телендә язылган. Текстның 2, 4, 5, 7, 11 һәм 17 нче юлларында гарәп язуында кыска сузыкларны белдерә торган хәрәкә билгеләре кулланылган. Тик аларның кулланылуы тотрыклы түгел. Мәсәлән, 5 нче юлда хәрәкәләр бик күп куелган булса, башка юлларның һәрберсендә бары тик берәр хәрефкә генә караган хәрәкә билгеләре бар. Болгар һәм Алтын Урда чоры кабер ташларындагы язуларда бик еш, ә Казан ханлыгы дәвере ташларында сирәгрәк кулланылган аерым бер төрле диакритик билгеләр («дәл», «ра» һәм «тый» хәрефләре астына берәр нокта кую күренеше) бу ташъязмада да бар. XVII гасырга караган, безгә билгеле бүтән һәм аннан соңгы чор татар эпиграфик истәлекләрендә мондый үзенчәлекле билгеләр эш тәжрибәбездә бүтән очрамады. Бу ташта уелган сүзләрнең ахырларындагы «йа» хәрефе астына икешәр нокта кую күренеше XVIII-XIX гасырлардагы татар эпиграфик истәлекләрендә, сирәгрәк булса да, күренгәли. Шул ук чорларда «син» хәрефе астына өчәр нокта кую гадәте ешрак күзәтелә. Сүзебез дәлилле булсын өчен Салагыш ташының әйтеп үтелгән палеографик үзенчәлекләрен төгәл күрсәтеп китик.

Бу ташъязмада «дәл» хәрефләренең астына берәр нокта тугыз урында куелган. Алар: 5, 9, 11, 14-17 юлларда. Болардан 14 һәм 16 юлларда икешәр мәртәбә.

«Ра» хәрефләре астында берәр нокта 5, 11 һәм 17 нче юлларда куелган. Болардан 11 нче юлда өч мәртәбә.

«Тый» хәрефе астында нокта куелган бердәнбер очрак 14 нче юлдагы «тугузда» сүзендә.

Ташъязманың 1, 5, 7, 10-13, 15-17 юлларында сүз ахырындагы «йа» хәрефләре астына икешәр нокта куелган уналты очрак билгеләнде. Шул исәптән, 12, 13 һәм 16 нчы юлларда икешәр, ә 11 нче юлда дүрт мәртәбә.

«Син» хәрефләре астына өчәр нокта кую 2, 4, 5, 7-10, 15-17 юлларда уникә мәртәбә очрый. (Сигезенче юлда ике тапкыр).

Таш текстында грамматик хаталар шактый булуын да әйтеп китәргә кирәк. Анда гарәп сүзләре бозыбрак язылганнар: аерым сүзләр һәм хәрефләр төшеп калган яисә урыннары буталган, хәрефләрнең нокталары ялгыш куелган һ. б. Эпитафиянең башка хаталары исә түбәндәгеләр.

Ташъязманың беренче юлында «әлхәйе» сүзе алдына язылырга тиешле «һуа» гыйбарәсе бөтенләй уелмаган. Өченче юл ахырындагы «һуа» сүзе бу урында артык.

Дүртенче юлда «көлли» сүзеннән соң язылырга тиеш булган «хәйе» сүзе уелмыйча калган.

Алтынчы юлда «арзи» сүзе алдындагы «би-әйи» сүзе дә язылмаган.

Сигезенче юлдагы «заикъәт» сүзеннән соң булырга тиешле «әл-мәүт» сүзе шулай ук төшеп калган. Шул ук юлдагы «ән-нәби» сүзенең «әл» артик-

ле уелмыйча калуы сәбәпле, «калә» һәм «ән-нәби» сүзләре хаталы рәвештә берберсенә кушып язылганнар.

Тугызынчы юлдагы «фәҗгалиһа» сүзе ялгыш «ф» урынына «т» белән һәм «тәжлгалиһа» дип, артык «ләм» хәрефе өстәп язылган.

Унынчы юлдагы «мизрагъәт» сүзенең «р» хәрефе уелмаган.

Унберенче юлда «би-игътибари» сүзенең берничә хәрефе төшеп калганлыктан, бу сүз хаталы язылган.

Унҗиденче юлда «даре» сүзе хаталы рәвештә язылган. Шул ук юлда «бәкага» сүзе дә ялгыш итеп «фәкага» дип уелган. Күрәсең, ташны уючы, ялгыш «фәна» дип яза башлап, әлеге сүзне бозгандыр.

Унсигезенче юлдагы «тәгалә» сүзенең «лә» иҗеге уелмаган.

17 нче һәм 18 нче юллардагы сүзләрнең урыннары үзара бутап уелган. Ягъни, 17 нче юлдагы «ли-л-фәнадин дарел-бәкага» гыйбарәсенең «кичте» дигән дәвамы 18 нче юлның ахырына язылган. Ул да хаталы итеп «киҗ те» рәвешендә уелган. Ә 18 юлдагы «Хакъ тәгалә» дип башланган гыйбарәнең «рәхмәт кыйлсын» дигән ахыргы өлеше 17 нче юлга «сикереп менгән». Болар буталмыйча язылган очракта, дөрес итеп «дарел-фәнадин дарел-бәкага кичте» һәм «Хакъ тәгалә рәхмәт кыйлсын» рәвешендә уелырга тиеш булганлыгы аңлашыла. Мондый төр хаталар борынгы дәверләрдәге ташларда еш күзәтелә. Хәер, хәзерге заман эпитафияләрендә дә хаталар һич аз түгел.

Салагыш ташъязмасындагы мәгълүматларны һәм архивларда саклана торган бай тарихи материалларны чагыштырып өйрәнү үткәннәрдәге билгесез вакыйгаларга шактый ачыклык кертте. Бу, гомумән, төрле тарихи чыганакларның бер-берсен тулыландыруына ачык дәлил булып тора, шул ук вакытта, өйрәнелмәгән катламнарның кызыклыгын һәм күплеген искәртә.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Мәрданов Р., Һадиев И. «Таш архив» серләре // Гасырлар авазы – Эхо веков. − 2002. − № 3/4. − Б. 65-75.
2. Ахметзянов М. О лексике татарских эпитафий XVII-XVIII вв. // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983. – С. 75-83.
3. Мәрданов Р., Һадиев И. «Таш архив» серләре... − Б. 72; Шулар ук. Әгерҗе төбәге тарихы. – Казан, 2003. – Б. 102; Шулар ук. «Яшәсәң дә җиһанда бер заман...» // Әгерҗем — йөрәк җырым. – Казан, 2004. – Б. 74.
4. Әхмәтҗанов М. Тарихи чыганаклар // Идел. – 1994. – № 2. – Б. 65.
5. Мәрданов Р., Һадиев И. Әгерҗе төбәге тарихы... – Б. 153-154.

63 нче биттәге рәсем 1658 елда куелган «Әүлия кабере» ташы. Ташъязманың график рәсемен ясаучы — Р. Мәрданов.

Раиф Мәрданов,
филология фәннәре кандидаты,
Ирек Һадиев,
Татарстан Милли китапханәсенең директор урынбасары

РЕЗЮМЕ

В статье исследователей Р. Марданова и И. Хадиева дается подробное описание и анализ текста татарского надгробия, датированного ноябрем 1658 г. и сохранившегося в д. Салауши Агрызского района Республики Татарстан. Информацию, содержащуюся в эпитафии, авторы дополняют сведениями из документов Российского государственного архива древних актов.